**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1780**
**22.03.2024**

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 19 октябрендәге 5650 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 19 октябрендәге 5650 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2596 номерлы, 2023 елның 23 июнендәге 5480 номерлы, 2023 елның 15 декабрендәге 12181 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын тормышка ашыруга чараларны финанслауны шәһәр бюджетында «Балаларга өстәмә белем бирү» 0703, «Мәдәният» 0801 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 1 553 658,49 мең сум: 2023 елда – 580 850,16 мең сум; 2024 елда – 483 311,15 мең сум; 2025 елда – 489 497,18 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | 2025 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 580 850,16 | 483 311,15 | 489 497,18 | 1 553 658,49 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджет | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 580 850,16 | 483 311,15 | 489 497,18 | 1 553 658,49»; |

- 4 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 22 мартындагы
1780 номерлы карарына
кушымта

4 бүлек. Тормышка ашыру срокларын һәм җаваплы башкаручыларны күрсәтеп, программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

«2023-2025 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2023-2025 елларга китапханә эшен үстерү (алга таба – ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Китапханә эше турында» 1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Законы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – мәдәният идарәсе) |
| Ярдәмче программаны үтәүчеләр | Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре |
| Ярдәмче программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Гражданнарга мәгълүматтан һәм белемнәрдән иркле файдалану мөмкинлегенә карата үзләренең конституциячел хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итә торган китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерү, шулай ук китапханә фондларын саклау һәм үстерү.<br>2. Мәгълүмати-китапханә хезмәтләреннән файдалануда һәм шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә тигез мөмкинлекләр тәэмин итү. |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2023 - 2025 еллар |

<table>
<tr><td rowspan="7">Еллар буенча бүлеп, ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Ярдәмче программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2023 ел<br>(мең сум)</td><td>2024 ел<br>(мең сум)</td><td>2025 ел<br>(мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чоры өчен барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>110 891,9</td><td>85 385,22</td><td>86 269,89</td><td>282 547,01</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>110 891,9</td><td>85 385,22</td><td>86 269,89</td><td>282 547,01</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">- шәһәр халкының уку ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен китапханә фондларын тулыландыру (берәмлек);<br>- шәһәр халкының уку ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен китапханәләрне вакытлы матбугат белән тулыландыру;<br>- шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, укуны популярлаштыру (берәмлек);<br>- шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, укуны популярлаштыру (кеше).</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="5">Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тотуны мәдәният идарәсе гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## Ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың эчтәлеге

Хәзерге вакытта «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУга капиталь ремонт таләп ителә. 18 шәһәр китапханәсе таләпләргә туры килә торган бина белән тәэмин итүгә мохтаҗ. Шәһәр китапханәләренә әдәбият керү күләме кими. Шәһәрнең 1 кешесенә китап белән уртача тәэмин ителеш бары тик 1,4 (Россия Федерациясендә - 7,0; Татарстан Республикасында - 6,0); 1 укучыга - 12 китап (Россия Федерациясендә - 17,5; Татарстан Республикасында - 16) тәшкил итә.

«2023-2025 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасы гражданнарга мәгълүматтан һәм белемнәрдән ирекле файдалану мөмкинлегенә карата үзләренең конституциячел хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итә торган китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерүгә, шулай ук китапханә фондларын саклау һәм үстерүгә юнәлдерелгән.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру мәдәният өлкәсендәге учреждение эшчәнлегендә булган кыенлыкларны җиңеп чыгарга, китапханә фондларын тулыландыру, шәһәр халкының уку ихтыяҗларын канәгатьләндерү, шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, укуны популярлаштыру өчен китапханә фондларын тулыландыру буенча максатчан эш алып барырга мөмкинлек бирәчәк. Ярдәмче программа интеллектуаль, иҗади, оештыру һәм финанс мөмкинлекләрен берләштерүне күздә тота.

«2023-2025 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, чаралары һәм финанслау

| № | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 19 | 10 | 11 |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| | Максат: Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | |
| | 1 бурыч. Гражданнарга мәгълүматтан һәм белемнәрдән ирекле файдалану мөмкинлегенә карата үзләренең конституциячел хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итә торган китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерү, шулай ук китапханә фондын саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | |
| 1 | Китапханә фондларын туган якны өйрәнү әдәбияты, җирле документлар, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның телләрендәге документлар белән комплектлаштыру | «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ | 2023-2025 еллар | Китапханә фондларына бер елда яңа килгән экземплярлар саны, бермлек | 135 | 125 | 115 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Шәһәр халкының уку ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен китапханә фондларын тулыландыру |
| 2 | Үзәк, республика һәм җирле матбугат басмаларына язылуны тәэмин итү | «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ | 2023-2025 еллар | Язылган басмаларның исемнәренең саны, берәмлек | 170 | 170 | 170 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | Шәһәр халкының уку ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен, китапханәләрне вакытлы басмалар белән тулыландыру |
| | 2 бурыч. Мәгълүмати-китапханә хезмәтләренең файдалану мөмкинлеген һәм шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә бертигез мөмкинлекләрне тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| 3 | Китапханә эшен үстерүгә һәм укуны популярлаштыруга юнәлдерелгән шәһәр массакүләм чаралар үткәрү | «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ | 2023-2025 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 21 | 22 | 23 | - | - | - | Шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, укуны популярлаштыру |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Китапханә эше өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) | «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ | 2023-2025 еллар | Китапханә чараларына килү саны, кеше | 76 000 | 76 500 | 77 000 | 99 841,91 | 84 335,22 | 85 219,89 | Шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, укуны популярлаштыру |
| 5. | «Мәдәният» илкүләм проектының «Культуралы мохит» федераль проекты | «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ | 2023 | Муниципаль китапханәне бердәм модельле стандарт буенча кабат җиһазландыру | 1 | - | - | 10 000,0 | - | - | Шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, укуны популярлаштыру |

«2023-2025 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2023-2025 елларга музей эшен үстерү (алга таба – ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Законы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – мәдәният идарәсе) |
| Ярдәмче программаны үтәүчеләр | Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре |
| Ярдәмче программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү |
| Ярдәмче программаның бурычы | 1. Музейларны һәм музей эшен үстерү һәм аларның җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак социомәдәни функцияләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру. Тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм куллану.<br>2. Мәдәни-агарту һәм белем бирү эшчәнлеге үткәрү. |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2023 - 2025 еллар |

<table>
<tr><td rowspan="7">Еллар буенча бүлеп, ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Ярдәмче программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2023 ел (мең сум)</td><td>2024 ел (мең сум)</td><td>2025 ел (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чоры өчен барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>30 436,94</td><td>26 674,42</td><td>26 972,80</td><td>84 084,16</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>30 436,94</td><td>26 674,42</td><td>26 972,80</td><td>84 084,16</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - фондларны тулыландыру, шәһәр рәссамнарына ярдәм итү, музей эшен популярлаштыру (берәмлек);<br>- гражданнарны мәдәни кыйммәтләргә тарту, халыкның музей хезмәтләренә ихтыяҗын канәгатьләндерү (процент);<br>- күргәзмәләр саны арту (берәмлек);<br>- музейга килүчеләр саны арту (кеше) |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тотуны мәдәният идарәсе гамәлгә ашыра |

Ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың эчтәлеге

«2023-2025 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы музей фондларын саклау, өйрәнү һәм комплектлаштыру, шулай ук аларның җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак социомәдәни функцияләрен мәдәни-агарту һәм белем бирү эшчәнлеге алып бару юлы белән тормышка ашыру өчен шартлар тудыру максатларында музей эшен үстерүне максат итеп куя.

Мәдәният һәм сәнгать үсеше өчен тискәре ситуацияне бюджетның тотрыклы дефициты да, халыкның реаль керемнәре кимү тенденциясен дә китереп чыгара. Шәһәр музей фондының (Тарихи-туган якны өйрәнү музее һәм Картиналар галереясы) һәм музейларның торышы һәм үсеше, мәдәни мирасны саклау һәм трансляцияләү өчен традицион урын буларак, таләпләргә туры килми. Музейларның начар техник җиһазланышы музей фондын компьютерлаштыруны нәтиҗәле үткәрергә мөмкинлек бирми. Ял итү мәдәният учреждениеләренең популярлыгы һәм әһәмияте кими.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру учреждениеләр эшчәнлегендә булган авырлыкларны җиңәргә, музей фондларын сакларга, өйрәнергә һәм комплектлаштырырга, шулай ук аларның җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак социомәдәни функцияләрен мәдәни-агарту һәм белем бирү эшчәнлеге алып бару юлы белән тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

«2023-2025 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, чаралары һәм финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| | Максат: Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | |
| | 1 бурыч. Музейларны һәм музей эшен үстерү һәм аларның җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак социомәдәни функцияләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм куллану | | | | | | | | | | |
| 1 | Музей коллекцияләрен тулыландыру, музей эшен модернизацияләү һәм популярлаштыру | «Яр Чаллы картиналар галереясы» МБУ, «Тарихи-туган якны өйрәнү музее» МАМУ | 2023-2025 еллар | Предметлар, чаралар исемнәренең саны (ким түгел), берәмлек | 1 | 1 | 1 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Фондларны тулыландыру, шәһәр рәссамнарына ярдәм күрсәтү, музей эшен популярлаштыру |
| | 2 бурыч. Мәдәни-агарту һәм белем бирү эшчәнлеге үткәрү | | | | | | | | | | |
| 2 | Мәдәни-белем бирү, фәнни-агарту максатларында музей фондыннан файдалануны активлаштыру | «Яр Чаллы картиналар галереясы» МБУ, «Тарихи-туган якны өйрәнү музее» МАМУ | 2023-2025 еллар | Төп фондның экспозициягә куела торган музей предметлары өлеше (барлык формаларда), % | 29 | 30 | 32 | - | - | - | Гражданнарны мәдәни кыйммәтләргә җәлеп итү, халыкның музей хезмәтләренә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү |
| 3 | Күргәзмә эшчәнлеген активлаштыру | | | Күргәзмәләр саны, берәмлек | 46 | 48 | 50 | - | - | - | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Музей эше өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) | | | Музейларга килү саны, кеше | 117 000 | 118 000 | 119 000 | 30 386,94 | 26 624,42 | 26 922,80 | |

«2023 - 2025 елларга муниципаль театр-тамаша учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның паспорты

<table>
<tr><td>Ярдәмче программаның исеме</td><td colspan="5">2023-2025 елларга муниципаль театр-тамаша учреждениеләрен үстерү (алга таба – ярдәмче программа)</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы)</td><td colspan="5">«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Законы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – мәдәният идарәсе)</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны үтәүчеләр</td><td colspan="5">Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаның максаты</td><td colspan="5">Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаның бурычы</td><td colspan="5">Профессиональ сәнгатьне саклау һәм үстерү, иҗат коллективларының һөнәри үсеше өчен шартлар тудыру</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2023 - 2025 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Еллар буенча бүлеп, ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Ярдәмче программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2023 ел (мең сум)</td><td>2024 ел (мең сум)</td><td>2025 ел (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чоры өчен барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>138 068,94</td><td>129 666,88</td><td>130 886,31</td><td>398 622,13</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>138 068,94</td><td>129 666,88</td><td>130 886,31</td><td>398 622,13</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - коллективларның иҗади эшчәнлеген үстерү, халыкның барлык яшь категорияләренең мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү, музыкаль, хореография сәнгатен популярлаштыру (сәг / елга);<br>- коллективның иҗади эшчәнлеген үстерү, халыкның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү (берәмлекләр);<br>- шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү (кеше) |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тотуны мәдәният идарәсе гамәлгә ашыра |

Ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың эчтәлеге

«2023 - 2025 елларга муниципаль театр-тамаша учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасы профессиональ сәнгатьне саклау һәм үстерүгә, иҗат коллективларының һөнәри үсеше өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Шәһәрнең профессиональ иҗат коллективлары бүгенге көндә шулай ук шәһәр иҗат коллективлары өчен уртак булган кыенлыклар кичерә: бу материаль-техник базаның начар булуы, гастроль эшчәнлеген тиешенчә финансланмау, грант ярдәме булмау.

Икенче яктан караганда, аларга бөтен мәдәният өчен дә хас булган барлык проблемалар да кагыла:

1) профессиональ сәнгатьне пропагандалау һәм тамашачылар мәдәниятен тәрбияләү буенча реклама чаралары системасының булмавы;

2) кадрлар проблемасы;

3) профессиональ коллективларның гастрольләрен оештыру системасы булмау.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру учреждениеләр эшчәнлегендәге кыенлыкларны җиңәргә, коллективларның иҗади эшчәнлеген үстерергә, халыкның барлык яшь категорияләренең рухи һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, музыкаль, хореография сәнгатен популярлаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

«2023-2025 елларга муниципаль театр-тамаша учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, чаралары һәм финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| | Максат: Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | |
| | 1 бурыч. Профессиональ сәнгатьне саклау һәм үстерү, иҗат коллективларның һөнәри үсеше өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | |
| 1 | Концертлар һәм концерт программалары күрсәтү | «Болгар» бию театры» МАМУ | 2023 – 2025 еллар | Чыгышлар саны, сәг./ел | 86 | 86 | 86 | - | - | - | Коллективларның иҗади эшчәнлеген үстерү, халыкның барлык яшь категорияләренең мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү, музыка, хореография сәнгатен популярлаштыру |
| 2 | | «Визит» джаз оркестры МАМУ | | | 86 | 86 | 86 | - | - | - | |
| 3 | | «Игорь Лерманның камера оркестры» МАМУ | | | 88 | 88 | 88 | - | - | - | |
| 4 | Спектакльләр күрсәтү | «Мастеровые» РДТ» МАМУ | 2023 - 2025 еллар | Спектакльләр саны, берәмлек | 227 | 227 | 227 | - | - | - | Коллективның иҗади эшчәнлеген үстерү, халыкның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Башкару сәнгате, театр эше өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) | «Болгар» бию театры» МАМУ | 2023 - 2025 еллар | Концерт, спектакльләргә килгән тамашачылар саны, кеше | 18 000 | 18 000 | 18 000 | 138 068,94 | 129 666,88 | 130 886,31 | Шәһәр халкының мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү |
| | | Визит» джаз оркестры МАМУ | | | 25 612 | 25 612 | 25 612 | | | | |
| | | «Игорь Лерманның камера оркестры» МАМУ | | | 25 612 | 25 612 | 25 612 | | | | |
| | | «Мастеровые» РДТ» МАМУ | | | 60 474 | 60 474 | 60 474 | | | | |

«2023 - 2025 елларга муниципаль концерт учреждениеләрен үстерү»
ярдәмче программасы

## Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2023-2025 елларга муниципаль концерт учреждениеләрен үстерү (алга таба – ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Законы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – мәдәният идарәсе) |
| Ярдәмче программаны үтәүчеләр | Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре |
| Ярдәмче программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | Милли, Россия, дөньякүләм музыка, цирк традицияләрен саклау һәм үстерү, заманча сәнгатьне үстерү |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2023 - 2025 еллар |
| Еллар буенча бүлеп, ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | |

| Финанслау чыганаклары | Ярдәмче программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | 2025 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чоры өчен барлыгы (мең сум) |
| Муниципаль бюджет | 129 822,51 | 88 913,01 | 89 893,39 | 308 628,9 |
| Федераль бюджет | | | | |
| Республика бюджеты | - | - | - | - |
| Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| Барлыгы | 129 822,51 | 88 913,01 | 89 893,39 | 308 628,9 |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Коллективларның иҗади эшчәнлеген үстерү, барлык яшьтәге халыкның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү (берәмлек; кеше). |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тотуны мәдәният идарәсе гамәлгә ашыра |

Ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың эчтәлеге

«2023 - 2025 елларга муниципаль концерт учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасы милли, Россия, дөньякүләм музыка, цирк традицияләрен саклау һәм үстерүгә, заманча сәнгатьне үстерүгә юнәлдерелгән.

Соңгы елларда җәмгыятьтә барган сәяси, икътисадый һәм тормышның социаль өлкәләрен камилләштерү процесслары мәдәни потенциал белән мәдәният өлкәсен материаль-техник һәм оештыру-хокукый яктан тәэмин итү торышы арасында тирән аерманы күрсәтте. Мәдәният һәм сәнгать үсеше өчен тискәре ситуацияне бюджетның тотрыклы дефициты да, халыкның реаль керемнәре кимү тенденциясен дә китереп чыгара

Кадрлар проблемасы төп проблемаларның берсе булып кала, чөнки мәдәният тармагының икътисадый потенциалын беренче чиратта хезмәт ресурслары билгели. Мәдәни-ял итү учреждениеләре кадрлар базасын ныгытуга мохтаҗ. Хезмәт хакы түбән булу сәбәпле, яшь белгечләр алда санап үтелгән учреждениеләргә бик теләп бармыйлар. Кадрлар потенциалын саклау һәм тулыландыру елдан-ел катлаулана бара.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру мәдәният өлкәсендәге учреждениеләр эшчәнлегендә булган кыенлыкларны җиңеп чыгарга, концерт һәм башка программаларны, сәхнә чыгышларын, цирк тамашаларын, номерларын булдыру һәм күрсәтү, концерт, цирк һәм башка программаларны, сәхнә чыгышларын оештыру һәм күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген бирәчәк. Программа интеллектуаль, иҗади, оештыру һәм финанс мөмкинлекләрен берләштерүне күздә тота.

«2023-2025 елларга муниципаль концерт учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, чаралары һәм финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| | Максат: Яр Чаллы шәһәре халкының мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | |
| | Бурыч. Милли, Россия, дөньякүләм музыка, цирк традицияләрен саклау һәм үстерү, заманча сәнгатьне үстерү | | | | | | | | | | |
| 1 | Концертлар һәм башка программалар, сәхнә чыгышлары күрсәтү | «Орган залы» МАМУ | 2023 - 2025 еллар | Концерт һәм башка программалар саны, берәмлек | 100 | 100 | 100 | - | - | - | Коллективларның иҗади эшчәнлеген үстерү, барлык яшьтәге халыкның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү |
| 2 | | «Сара Садыйкова исемендәге концертлар залы» МАМУ | | Концерт һәм башка программалар саны, берәмлек | 150 | 150 | 150 | - | - | - | |
| 3 | Цирк тамашалары һәм номерлары ясау һәм күрсәтү | «Яр Чаллы филармониясе» МБМУ | 2023 - 2025 еллар | Тамашалар, номерлар саны, берәмлек | 12 | 14 | 14 | - | - | - | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Концерт, цирк һәм башка программалар, сәхнә чыгышлары әзерләү, оештыру һәм күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү | «Орган залы» МАМУ | 2023 - 2025 еллар | Концерт һәм башка программаларга килгән тамашачылар саны, кеше | 43 000 | 43 000 | 43 000 | 129 822,51 | 88 913,01 | 89 893,39 | |
| | | «Сара Садыйкова исемендәге концертлар залы» МАМУ | | | 106 000 | 106 000 | 106 000 | | | | |
| | | «Яр Чаллы филармониясе» МБМУ | | | 11 000 | 11 000 | 11 000 | | | | |

«2023 - 2025 елларга мәдәни-ял учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның паспорты

<table>
<tr><td>Ярдәмче программаның исеме</td><td colspan="5">2023-2025 елларга мәдәни-ял учреждениеләрен үстерү (алга таба – ярдәмче программа)</td></tr>
